ГЛАВА
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский район
422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст. поселогы ,
Чүпрәле районы
422490

Тел.: (84375) 3-17-45, 3-17-03, факс: (84375) 3-17-45, e-mail: Nbur.Drz@tatar.ru,
www. Nbur -drogganoe.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.06.2015 № 16

Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керүгә бәйле рәвештә карар бирәм:

1. Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге административ регламентларын расларга: Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта);

Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта);

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта);

Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарның һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларының үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен милкенә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта);

Дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеген милеккә бирү яисә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты, җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә (5 нче кушымта);

Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта);

Гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, дача, гражданнар һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (аренда) (7 нчы кушымта).

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегенә урнаштырырга.

3. Әлеге карар кабул ителгән вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Борындык авыл
җирлеге башлыгы В.Г. Ранцев